ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май, 2019 ел № 31/5

Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар планы чорына бюджеты турында» 28/5 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар планы чорына бюджеты турында» 28/5 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/4, 2019 елның 25 февралендәге 30/5 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 пунктның 1 пунктчасында:

– икенче абзацта «8 689 088,59» саннарын «8 783 233,36» саннарына алыштырырга;

– өченче абзацта «9 197 588,85» саннарын «9 383 968,61» саннарына алыштырырга;

– дүртенче абзацта «508 500,26» саннарын «600 735,25» саннарына алыштырырга;

2) 13 пунктның 1 пунктчасында:

– беренче абзацта «3 311 924,29» саннарын «3 379 078,29» саннарына алыштырырга;

– унынчы абзацта «7 005,70» саннарын «7 053,9» саннарына алыштырырга;

– түбәндәге эчтәлектәге унсигезенче абзац белән тулыландырырга:
«– опекага (попечительлеккә) бирелгән ятим балаларны һәм ата- ана каравыннан мәхрүм калган балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә, үз

вазыйфаларын башкаручы опекун яки попечительләргә акчалата түләүне билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 67 105,80 мең сум күләмендә субвенция;»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 15.1 пункты белән тулыландырырга:

«15.1. Шәһәр бюджетында территориаль иҗтимагый үзидарә рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән 17 235,9 мең сум күләмендәге субсидияне исәпкә алырга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 мартындагы 625-р санлы боерыгы нигезендә»;

4) түбәндәге эчтәлектәге 16.1 пунктын өстәргә:

«16.1. шәһәр бюджетында исәпкә алырга:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 елның 1 июнендәге 391 санлы карары нигезендә 2019 елда уздырылган республика конкурсында җиңүчеләр һәм призерлар дип танылган территориаль иҗтимагый үзидарәләргә Татарстан Репсубликасы бюджетыннан кергән 9 542,00 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертларны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендәге 964-р санлы боерыгы нигезендә;

2) һөнәри керемгә салым хисабыннан формалашкан һәм Яр Чаллы шәһәренең социаль әһәмияткә ия объектларын төзекләндерүгә һәм ремонтлауга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы бюджетыннан 168,45 мең сум күләмендә кергән башка бюджетара трансфертларны.»;

5) 19 пунктның бишенче абзацында «керемнәр кермәгәндә» сүзләреннән соң «һәм (яйсә) чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (кайтару)» дип өстәргә;

6) түбәндәге эчтәлектәге 21.1 пункты белән тулыландырырга:

«21.1 2019 елда Яр Чаллы шәһәренең «Электротранспорт» муниципаль унитар предприятиесен 2018 елда алынган чиста табышның 50 проценты күләмендә салым һәм башка мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң калган табыш өлешен шәһәр бюджетына күчерүдән азат итәргә.»;

7) әлеге Карарның 1-5 нче кушымталары нигезендә 1 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 2 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 4 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 6 нчы, 8 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев